# **Хәерле булсын!**

*1 куплет:*

Хәерле булсын иртәләр!

Уңышлы булсын көннәр!

Күктә елмайган кояштай

Балкысын безнең йөзләр.

*2 куплет:*

Хәвеф-хәтәр очрамасын

Йөргән юлларыбызда.

Гел яхшылык кына булсын

Күңел-уйларыбызда.

*3 куплет:*

Үпкәләшмик юкка-барга.

Шөкер кылыйк булганга.

Сугыш, ачлык күрсәтмәсен

Ходай тәгалә безгә.

*Кушымта:*

Исән булыйк, исән булыйк,

һәммәбез дә сөеп яшик!

Бердәмлеккә, татулыкка,

Дус яшәүгә ни җитә.

*Кода:*

Бердәмлеккә, татулыкка, *(2 тапкыр)*

Һәммәбез дә

Яшик бу җирдә!